СОВЕТ
НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯР БУЕ МОРКВАШЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

30.07.2020 с. Набережные Моркваши 95-411

Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Моркващы авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы И.Х. Гаязов мәгълүматын тыңлаганнан соң, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советы, гамәлдәге кануннар үзгәрүгә бәйле рәвештә, җирлек Советы тарафыннан хупланып, Җирлекнең мәгълүмат стендларында халыкка игълан ителде, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырылды һәм җирлек халкы белән гавами тыңлауларда фикер алышуның барлык кирәкле процедураларын узып «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты эшләнүен билгеләп үтте.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, шулай ук «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законның 44нче статьясы һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004нче елның 28нче июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7нче статьясы, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Уставының 20, 86-88 статьялары нигезендә

Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Уставына 1нче кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Уставының яңа редакциясен расларга.
3. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.
4. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән срокларда үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Яр Буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы И. Х. Гаязов

Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Морквашы авыл җирлеге
Советының 2020 нче елның
30нчы июлендәге 95-411нче
номерлы карарына
1 нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге
Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр

1. Уставның 30нчы статьясындагы 3нче пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Авыл җирлеге Советы депутатына үз вәкаләтләрен даими рәвештә гамәлгә ашыру өчен, айга алты эш көненнән дә ким булмаган чорда эш урынын (вазыйфаларын) саклау гарантияләнә»;

2. Уставның 50нче статьясындагы 2нче пунктының 13нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« - хуҗасыз хайваннар белән эш итү буенча эшчәнлекне тормышка ашырганда чаралар оештыра»;

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Яр Буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы И. Х. Гаязов